**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылындагы торак пунктта гражданнар җыены карары**

10.11.2025 ел, № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылындагы гражданнар җыены
карар кылды:

2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Иркен авылында Гафиятуллин, Ибраһимов урамнары буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган яисә суд карары буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылган затлардан, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан; срочный хезмәттәге хәрби хезмәткәрләр; мобилизация буенча чакырылган махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.Җыелган акчаларны һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзекләндерүгә, аларга якын территорияне төзекләндерүгә (проектка заказ бирү, иске һәйкәлне сүтү һәм Иркен авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга яңа һәйкәл куюга юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче, «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Башлыгы» ___________ И. И. Җәләев**